ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru


---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

13.12.2024 № 1124

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районында мәгълүмат киңлеге инфраструктурасын камилләштерү, халыкка тапшырыла торган мәгълүматның сыйфатын һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү буенча массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1812 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Кадрлар составы үзгәрүгә бәйле рәвештә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районында мәгълүмат киңлеге инфраструктурасын камилләштерү, халыкка тапшырыла торган мәгълүматның сыйфатын һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү буенча массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1812 номерлы карары белән расланган «Биектау муниципаль районында мәгълүмат киңлеге инфраструктурасын камилләштерү, халыкка тапшырыла торган мәгълүматның сыйфатын һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү буенча массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты чаралары исәбеннән субсидияләр бирү буенча комиссия составы» дип аталган 2 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Комиссия составыннан Шәйдуллин Дамир Фәритовичны – Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен – комиссия рәисен чыгарырга.

1.2. Комиссия составына Хәкимуллин Рамил Фатыйховичны – Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен – комиссия рәисен кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Биектау муниципаль районының

Интернет челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып игълан итәргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Хәкимуллин